**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Мортыштамак авыл җирлеге Мортыштамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак 2023 елның 28 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 28 октябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

« 1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (яктырту челтәрләрен ремонтлау, Мортыштамак урамнарын яктырту җайланмасы (яктырткычлар, кабель сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү),

2. Мортыштамак торак пунктында, торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (махсус техниканы карап тоту - ГСМ сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); (вак ташлы-комлы катнашма сатып алу, чокырлы ремонт, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), Комсомол урамы һәм Совет урамы буенча Мортыштамак торак пунктында; вак таш өслекле өслекне ремонтлау (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташый торган урынга күчерү һәм салу) Молодежная ур., Совет ур., Комсомол ур.,;

3. Мортыштамак торак пунктында халыкның күпләп ял итү урынын (Д. Әхмәтов исемендәге парк) ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү (ГСМ бензин сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

Мортыштамакторак пунктында Минзәлә елгасы аша җәяүлеләр күперен төзү һәм ремонтлау (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4. Традицион күмелгән урыннарны ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (Мортыштамак торак пунктында Комсомол урамы буенча зират территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма кую эшләре өчен түләү);
Мортыштамак торак пунктында Совет урамы буенча зират территориясендә зур буйлы агачларны кисү (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Һадиуллин И.Н.